Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

23 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 22 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. « Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Чуаш Сәрәне авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив халәткә китерү, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелек өчен түләүгә?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Чуаш Сәрәне авылы, Үзәк урамы, 34а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Халык җыенында рәислек итүче
Сәрән авыл җирлеге башлыгы Д.А.Севастьянов